Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданнар Ә.С. Насыйрова, Д.В. Кузнецова, З.И. Михайлова, О.М. Зыятдинова һәм К.Ф. Галләмова шикаятьләренә бәйле рәвештә «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап торкан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарына 1 нче кушымтаның аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2017 елның 21 ноябре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарына 1 нче кушымтаның конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданнар Ә.С. Насыйрова, Д.В. Кузнецова,

З.И. Михайлова, О.М. Зыятдинова һәм К.Ф. Галләмова шикаятьләре сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Шикаятьләр бер үк предметка кагылышлы булганга күрә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 50 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге шикаятьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерде.

Докладчы судья А.Р. Шакараев мәгълүматын, яклар — гражданнар Д.В. Кузнецова, З.И. Михайлова, О.М. Зыятдинова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты юридик бүлеге башлыгы урынбасары Р.Н. Сафин, суд утырышына дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча чакырылган белгеч — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе урынбасары Р.Б. Гарипова аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Р.В. Сидаков, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы М.М. Сафина, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге баш белгече Э.И. Гафиятуллина, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле —

Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге прокуроры А.А. Яруллин, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлегенең әйдәүче консультанты Р.Р. Мингалиев чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданнар Ә.С. Насыйрова, Д.В. Кузнецова, З.И. Михайлова, О.М. Зыятдинова һәм К.Ф. Галләмова «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап торткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарына 1 нче кушымта (алга таба шулай ук — 1 нче кушымта) белән үзләренең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр белән мөрәҗәгать иттеләр.

Дәгъвалана торган кушымта белән социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 30 июненә кадәр торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме хезмәт төрләре буенча билгеләнгән.

Шикаятьләрдән, өстәмәләрдән һәм аларга кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүчеләр — идарә итүне идарәче компания башкара торган күпфатирлы йортлардагы торак

урыннар милекчеләре. Ләкин күрсәтелгән күпфатирлы йортларда торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме милекчеләр тарафыннан билгеләнмәгән һәм карала торган норматив хокукый акт белән расланган тарифлар буенча хисаплана.

Мөрәҗәгать итүчеләр билгеләгәнчә, 1 нче кушымта белән торак урыннарны карап тоту өчен түләү күпфатирлы йортларның конструктив һәм техник параметрларын, шул исәптән тузу дәрәҗәсен, катлар санын, лифтларның булу-булмавын, диварлар һәм түбә материалын һәм башка параметрларны исәпкә алмыйча Казан шәһәренең бөтен торак фонды өчен бер күләмдә билгеләнә. Шул ук вакытта, алар фикеренчә, торак урынны карап тоту өчен түләү күләме һәр күпфатирлы йорт өчен индивидуаль рәвештә билгеләнергә тиеш. Үзләренең позициясен дәлилләп, гражданнар Ә.С. Насыйрова, Д.В. Кузнецова, З.И. Михайлова, О.М. Зыятдинова һәм К.Ф. Галләмова, аерым алганда, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 17 мартындагы 7513-ОЛ/04 номерлы хатына сылтама бирәләр, аның эчтәлегеннән аңлашылганча, җирле үзидарә органнары тарафыннан урыннар милекчеләренә торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме билгеләнгәндә шул исәптән конкрет күпфатирлы йортның конструктив элементларын һәм үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүчеләр Татарстан Республикасы Конституция судыннан «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарына 1 нче кушымтаны Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорыйлар, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль һәм мөлкәти хәленә һәм

башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; хосусый милек хокукы закон белән саклана; Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый; кулланучылар товар җитештерүчеләрнең, хезмәт күрсәтүчеләрнең китергән зыянын законда билгеләнгән тәртиптә түләттерергә хокуклы.

1 нче кушымта Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының дәгъвалана торган карарының 1 пункты нигезендә 2017 елның 30 июненә кадәр гамәлдә булган дип санала һәм бу эшнең Татарстан Республикасы Конституция судының ачык утырышында карала башлау вакытына фактта үз көчен югалта. Әмма әлеге хәл үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан мөрәҗәгать итүчеләр дәгъва белдерә торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү өчен киртә була алмый, чөнки «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы я аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш туктатылырга мөмкин, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылган очраклар керми. Моннан тыш, дәгъвалана торган хокукый җайга салу асылы буенча шушы ук карарга 2 нче кушымтаның норматив нигезләмәләрендә сакланган, ул 2017 елның 1 июленнән гамәлгә кертелгән һәм шул исәптән гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә шундый түләү күләмен тиңдәш рәвештә билгели, шулай ук аны кертү өчен норматив-хокукый нигез булып тора.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан

Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше һәм 68 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала; бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән орган актының конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карарлар кабул итә. Карар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарына 1 нче кушымтаның гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә шундый түләү күләмен билгели торган аерым нигезләмәләре, мөрәҗәгать итүчеләр фикеренчә, шул түләүне хисаплаганда, конкрет күпфатирлы йортларның конструктив элементлары һәм үзенчәлекләреннән чыгып, дифференциацияләнгән алымны күздә тотмаганга күрә, әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Дәгъвалана торган хокукый нигезләмәләр торак законнары мәсьәләләренә кагыла, алар Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «к» пункты) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 һәм 5 өлешләр) буенча Россия Федерациясе субъектларының әлеге өлкәдәге законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнар нигезендә кабул ителә һәм аларга каршы килә алмый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре үзләренең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, мондый күләм җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы беренче өлешенең 6 пункты белән җирле үзидарә органнары компетенциясенә шул исәптән торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кертелгән. Эчтәлеге буенча тиңдәш нормалар «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы беренче өлешенең 6 пункты һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 8 статьясындагы беренче өлешенең 6 пункты белән беркетелгән.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы беренче өлеше, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясындагы беренче өлеше белән үзара бәйләнештә 40 статьясының өченче өлешендәге 17 пункты буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, шул исәптән җирле үзидарә органнарының торак мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләренә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, башка федераль законнар, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән кертелгән мәсьәләләрне хәл итү йөкләнгән Казан шәһәре җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә органы булып тора.

Шулай итеп, «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан

өчен түләү күләме турында» 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарны кабул итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтен законлы рәвештә гамәлгә ашырган, әлеге вәкаләт Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйләнештәге 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларына нигезләнгән, алар буенча җирле үзидарә органнары, закон нигезендә һәм үзләренә җаваплылык алып, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен тәэмин итәләр.

3. Татарстан Республикасын хокукый дәүләт дип игълан итеп, Татарстан Республикасы Конституциясе Татарстан Республикасына кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен иң зур хәзинә буларак тану, үтәү һәм яклау бурычын йөкли (1 статьяның беренче өлеше һәм 2 статья). Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясе Россия Федерациясе гражданнары Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы Конституциясе, халыкара хокукның гомумтанылган принциплары һәм нормалары нигезендә барлык хокукларга һәм ирекләргә ия һәм бертигез бурычлы, дип беркетә (22 статья). Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый (51 статья). Күрсәтелгән конституциячел нигезләмәләр шулай ук Татарстан Республикасының торак өлкәсендә гамәлгә ашырылалар һәм торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны җайга салу мәсьәләләре буенча кабул ителә торган шул исәптән җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары эчтәлеген һәм мәгънәсен билгелиләр.

Россия Федерациясе Граждан кодексы, әгәр законда яисә шартнамәдә башкача каралмаган булса, милекче үз карамагындагы мөлкәтне карап тоту бурычын үз өстенә ала, дип билгели (210 статья). Күрсәтелгән нормага Россия Федерациясе Торак кодексының 39 һәм 158 статьялары нигезләмәләре тиңдәш булып торалар, алар нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре үз карамагындагы торак урынны, шулай ук күпфатирлы

йорттагы гомуми мөлкәтне карап тотуга чыгымнарны торак урынны карап тоту өчен түләү кертү юлы белән үз өсләренә алырга тиеш.

Әлеге түләү күләмен билгеләүгә өстенлекле хокукны Россия Федерациясе Торак кодексы турыдан-туры күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренә бирә. Шулай, Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясындагы 7 өлеше нигезендә торак милекчеләре ширкәте яисә торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган куллanучылар кооперативы төзелмәгән күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту өчен түләү күләме андый йорттагы урыннар милекчеләренең әлеге Кодексның 45—48 статьялары белән куелган тәртиптә үткәрелә торган гомуми җыелышында билгеләнә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләре (алга таба — Кагыйдәләр) нигезендә торак урынны карап тоту өчен түләү күләме конкрет йортны карап тоту буенча хезмәтләр һәм эшләрнең күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре раслаган исемлегенә, күләменә һәм сыйфатына ярашлы булырга тиеш (35 пункт). Шул ук вакытта күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр һәм эшләр исемлеген, аларны күрсәтү һәм үтәү шартларын, шулай ук аларны финанслау күләмен, Кагыйдәләрнең 11(1) һәм 17 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре буенча, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр һәм эшләрнең минималь исемлеген (алга таба — Минималь исемлек) исәпкә алып, урыннар милекчеләре гомуми җыелышта расларга тиеш.

Шул ук вакытта күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең торак өлкәсендә бәяләр билгеләүне җайга салуга хокукларының өстенлеген гомуми кагыйдә буларак беркетеп, Россия Федерациясе Торак кодексында аннан чыгармалар да бар, алар күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре

ягыннан тиешле ихтыяр белдерү булмавына бәйле. Аерым алганда, Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше һәм Кагыйдәләрнең 36 пункты нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре гомуми җыелышта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән булсалар, җирле үзидарә органнары күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре торак урынны карап тоту өчен кертә торган түләү күләмен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары белән расланган тиешле эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы затлар башкара торган хезмәтләр һәм эшләр исемлегенә кергән хезмәтләр һәм эшләр бәясеннән чыгып билгелиләр.

Күрсәтелгән нормаларның сүзгә-сүз эчтәлегеннән аңлашылганча, җирле үзидарә органнары тарафыннан торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүдә һәр конкрет күпфатирлы йортка карата дифференциацияләнгән алым кулланылганчыга кадәр милекчеләр гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр һәм эшләр исемлеген раслау бурычын үтәргә тиешләр. Моңа Кагыйдәләрне куллану турында аңлатмалар бирергә вәкаләтләнгән Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хезмәт министрлыгы хатларында да күрсәтелгән, аларның мәгънәсе буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен Кагыйдәләр, Минималь исемлек һәм гомуми мөлкәтне карап тотуга таләпләр каралган башка норматив хокукый актлар нигезләмәләрен исәпкә алып, урыннар милекчеләре билгеләгән хезмәтләр һәм эшләрнең конкрет төрләреннән чыгып кую рөхсәт ителә һәм ул һәр күпфатирлы йорт өчен идарә итүдә икътисади яктан нәтиҗәлерәк була (2016 елның 17 мартындагы 7513-ОЛ/04 номерлы һәм 2016 елның 30 декабрендәге 45099-АЧ/04 номерлы хатлар).

Шул ук вакытта гамәлдәге законнар урыннар милекчеләре торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүгә хокукларын кулланмыйча гына калмыйча, гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча

хезмәтләр һәм эшләр исемлеген раслау бурычларын да үтәмәгән очракта җирле үзидарә органнарының торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен ни рәвешле билгеләргә тиешлеген регламентлаштырмый. Тикшерелә торган эшкә карата югарыда китерелгән хокукый җайга салудан шул аңлашыла: ул очракта Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты, Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезләмәсен гамәлгә ашырганда, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен Кагыйдәләр һәм Минималь исемлек нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләргә хокуклы булган. Монда дәгъвалана торган акт нормалары гамәлдәге законнар системасында җирле үзидарә органнары актлары белән күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр һәм эшләр исемлекләре, шулай ук аларны финанслау күләме расланган булырга тиеш булган конкрет күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карарларын алыштыру мөмкинлеген күздә тотмыйлар. Өстәвенә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының район администрацияләре һәм Торак-коммуналь хуҗалык комитеты дәгъвалана торган карарның 6 пунктын үтәү йөзеннән, торак урыннар милекчеләре хезмәтләр исемлеген һәм күпфатирлы йорттагы торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү мәсьәләсе буенча җыелышлар үткәргән вакытта, аларга методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә тиеш.

Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килә: дәгъвалана торган хокукый җайга салу үзенең хокукый табигате һәм асылы буенча торак урыннар милекчеләре тарафыннан тиешле карарлар кабул ителгәнчегә кадәр югарыда күрсәтелгән түләү күләмен билгеләүнең альтернатив ысулы булып кына тора, аны билгеләү Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә торак фондын тиешле рәвештә саклау, шул исәптән коммуналь комплекс оешмаларының туктаусыз һәм хәвефсез эшләвен тәэмин итү кирәклеге белән бәйле. Дәгъвалана торган акт Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан

күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең үз хокукларыннан файдаланмаган һәм торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүгә кагылган мәсьәләләрне мөстәкыйль рәвештә җайга салмаган булулары белән билгеләнгән үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән, гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү өлкәсендәге гамәлдәге торак законнары белән каралган гарантияләр дәрәҗәсен саклый һәм аларга федераль законнар белән каралмаган нинди дә булса башка өстәмә бурыч йөкләнүен күздә тотмый.

Мондый нәтиҗә Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килеп тора, ул берничә тапкыр күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше нигезендә җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йорттагы торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү буенча вәкаләт бирү күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре тарафыннан әлеге түләүне мөстәкыйль рәвештә билгеләү хокукын тормышка ашыруга комачауламый, чөнки җирле үзидарә органнарының күрсәтелгән вәкаләтен гамәлгә ашыру күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең тиешле ихтыяр белдерүләренең булмавы белән аңлатыла. Әлеге закон нигезләмәсе торак-коммуналь хуҗалыгының тиешле рәвештә эшләп торуын тәэмин итүгә юнәлгән, бу исә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең дә, торакка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрендә башка торучыларның да мәнфәгатьләренә туры килә. Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше җирле үзидарә органнары тарафыннан ирекле карарлар кабул ителү мөмкинлеген күздә тотмый. Торак урынны ремонтлау һәм карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү вәкаләтен гамәлгә ашырып, җирле үзидарә органнары торакка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрендә торучылар мәнфәгатьләренең балансын саклау максатында пропорциональлек һәм тәңгәллек критерийларына таянырга тиеш (2011 елның 22 мартындагы 357-О-О номерлы; 2016 елның 25 февралендәге 325-О номерлы билгеләмәләр).

Шуңа бәйле рәвештә дәгъвалана торган җайга салуны, мөрәҗәгать

итүчеләр дәлилләренә каршы, ул һәр конкрет күпфатирлы йортка карата торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләүгә дифференциацияләнгән алымны күздә тотмаган дәрәҗәдә гражданнар хокукларын боза торган буларак карарга ярамый. Өстәвенә, дәгъвалана торган карарның 7 пункты турыдан-туры шуны күздә тота: 1 нче кушымта нигезендә расланган күрсәтелгән түләү күләме күрсәтелә торган хезмәтләрнең составына һәм күпфатирлы йортның конструктив үзенчәлекләренә бәйле рәвештә исәпләнә һәм үзгәрә.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: карала торган карарның 7 пункты Кагыйдәләрнең 11 пункты белән аерылгысыз норматив берлектә, аның нигезендә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр һәм эшләр аның составына, конструктив үзенчәлекләренә, гомуми мөлкәтнең физик тузу дәрәҗәсенә һәм техник торышына, шулай ук күпфатирлы йортның геодезик һәм табигый-климатик урнашу шартларына бәйле рәвештә билгеләнәләр. Әлеге эшкә карата бу шуны аңлата: торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләме күпфатирлы йортның конструктив үзенчәлекләренә генә түгел, ә зуррак юридик көчкә ия булган акт белән беркетелгән башка параметрларга да бәйле рәвештә хисапланырга һәм үзгәрергә тиеш. Әлеге алым күрсәтелгән түләү күләмен милекчеләр үзләре билгеләгәндә дә, шулай ук җирле үзидарә органнары раслаган шундый түләү күләмен хисаплаганда һәм үзгәрткәндә дә исәпкә алынырга тиеш.

Шулай итеп, «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап токкан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарына 1 нче кушымтаның гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә шундый түләү күләмен билгели торган дәгъваланучы нигезләмәләре үзләренең бу Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый

мәгънәсе буенча гамәлдәге хокукый җайга салу системасында күпфатирлы йорттагы торак һәм торак булмаган урыннарны тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә юнәлгән, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең шундый түләү күләмен мөстәкыйль рәвештә җайга салу хокукларын гамәлгә ашыруга комачауламыйлар, аны хисаплаганда дифференциацияләнгән алымны куллану мөмкинлеген рөхсәт итәләр һәм шуңа бәйле рәвештә үзләреннән-үзе кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына каршы килмиләр.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «2017 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5320 номерлы карарына 1 нче кушымтаның гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә шундый түләү күләмен билгели торган нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми дип танырга, чөнки әлеге нигезләмәләр үзләренең бу Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гамәлдәге хокукый җайга салу системасында күпфатирлы йорттагы торак һәм торак булмаган урыннарны тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә юнәлгән, күпфатирлы йорттагы

урыннар милекчеләренең шундый түләү күләмен мөстәкыйль рәвештә җайга салу хокукларын гамәлгә ашыруга комачауламыйлар һәм аны хисаплаганда дифференциацияләнгән алымны куллану мөмкинлеген рөхсәт итәләр.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә бу Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 76-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**